ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат хакында

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе Ю.С. Никитинның Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә тәкъдим итәргә:

2.1. Түбәндәгеләрнең нәтиҗәлелеген арттыруны:

Татарстан Республикасы территориясендә элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә законнар үтәлешенә дәүләт контроленең һәм күзәтчелегенең;

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәү өлешендә үз вәкаләтләрен башкарганда мәгълүмат алмашу, эшчәнлекне координацияләү мәсьәләләре буенча башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасында иҗтимагый һәм башка оешмалар белән хезмәттәшлек системасының;

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең цифрлы сервисларының өстенлеге турында халыкка мәгълүмат бирүнең.

2.2. Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең канәгать булу дәрәҗәсен арттыру эшен дәвам итүне.

2.3. Вакантлы вазыйфаларга хезмәткәрләр алуны тәэмин итүне, кадрлар составын туплау буенча планлы эшне дәвам итүне.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына Татарстан Республикасында элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә законнар үтәлеше торышы турында мәсьәләне утырышта карарга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 2 ноябре
№ 2214-VI ДС